ЯКШӘМБЕ
7
МАРТ
1943 ел.
№ 54 (6776)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘһӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘһӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ЯШӘСЕН ХАЛЫКАРА КОММУНИСТИК ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ!

Без быел, халыкара коммунистик хатын-кызлар көнен — 8 нче мартны фашист басып алучыларга каршы ватан сугышының хәлиткеч моментында каршылыйбыз. Героик Кызыл Армиябез уңышлы рәвештә һөҗүм итә, немец-фашист гаскәрләренә һәм аларның ялчыларына каршы бер-бер артлы җимергеч ударлар ясый, аның җанлы көчләрен һәм техникасын тар-мар итә, юк итә.

Ватан сугышының беренче көннәреннән үк, совет хатын-кызлары, барлык халкыбыз белән берлектә, илебезнең азатлыгын, бәйсезлеген, Октябрь революциясе казганышларын саклау өчен дошманга каршы көрәшкә бердәм рәвештә күтәрелделәр. Меңнәрчә совет патриоткалары Кызыл Армия сафларында, партизан отрядларында үз-үзләрен аямыйча дошманга каршы сугышалар. Без аларны разведчиклар, снайперлар, врачлар, медсестралар сафында, элемтәче, һава һөҗүменнән саклану хезмәтләрен үтәүчеләр арасында һәм башка эшләрдә күрәбез.

Безнең хатын-кызларыбыз туган Кызыл Армиябез турында, фронтовикларның семьялары турында тирән кайгыртучанлык күрсәтәләр. Танклар колоннасы, самолетлар эскадрильясы төзү өчен средстволар туплауда, батыр сугышчыларга җылы киемнәр җыюда һәм аларга бүләкләр әзерләүдә актив катнашалар, яралы сугышчыларны тәрбиялиләр, аларның тормышларын саклап калу өчен бик күп алдынгы патриоткалар донорлар булып торалар.

Бездә фронт һәм тыл бердәм. Фронтта Кызыл Армиянең уңышлары, тылда безнең нечек эшләвебезгә бәйләнгән. Совет хатын-кызлары моны бик яхшы аңлыйлар. — Бөтенесе дә фронт өчен! Бөтенесе дә дошманны тизрәк тар-мар итү һәм юк итү өчен!

Безнең хатын-кызлар әнә шул лозунг астында предприятиеләрдә, транспортта, авыл хуҗалыгында һәм башка тармакларда армый-талмый эшләп, хезмәт җитештерүчәнлегенең гүзәл үрнәкләрен бирәләр.

Ләкин без бу ирешелгәннәр белән һич тә масаймаска, тынычланмаска тиешбез. Безнең алда тагын да зур бурычлар тора. Ватан сугышы әле дәвам итә. Безнең гаскәрләребезнең ударларына дошман котырынган рәвештә каршылык күрсәтә. Явыз дошманны тар-мар итү һәм юк итү өчен бездән тагын да күп тапкырлар арттырылган энергия белән эшләү таләп ителә. Предприятиеләрдә, транспортта эшләүче хатын-кызлар үзләренең бөтен көчләрен, энергияләрен биреп күбрәк танклар, самолетлар, миномётлар, пулеметлар, винтовкалар, сугыш припаслары җитештерү өчен көрәшергә, катлаулы профессияләрне һәм хәрби белемне үзләштерергә тиешләр.

Колхозчы хатын-кызлар алдында, 1943 нче елгы язгы чәчүне уңышлы үткәреп, ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарларын төгәл үтәп, Кызыл Армиябезгә кирәк булган барлык продуктларны бирү, промышленностьны чимал белән тәэмин итү бурычы тора.

«Ватан сугышының хәзерге хәлиткеч моментында совет халкыннан һәм совет хатын-кызларыннан дошманны тар-мар итү өчен, барлык көчләрне тагын да күбрәк бирү таләп ителә. Кызыл Армия һөҗүм сугышлары алып баруны, немецларны совет җиреннән кууны дәвам иттерә. Ләкин дошман көчле әле, ул ярсынып каршылык күрсәтә. Гитлер Германиясенә каршы көрәш әле вакыт таләп итә, корбаннар таләп итә, көчләребезне җигүне һәм барлык мөмкинлекләребезне туплауны таләп итә.

Хатын-кызлар хезмәтенең барлык резервларын тулысынча тупларга кирәк. Үз-үзеңне аямыйча эшләү—һәрбер совет хатын-кызының изге бурычы». (ВКП(б) Үзәк Комитеты карарыннан).

Ленин-Сталин партиясе җитәкчелегендә азатлык, бәйсезлек һәм тулы хокук яулап алган совет хатын-кызлары ватаныбызны саклау өчен, кешелек дөньясының явыз дошманы—фашизмны тар-мар итү өчен үзләренең барлык көчләрен бирерләр. Җиңү, һичшиксез, безнең якта булыр!

Немец оккупантларына үлем!

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

СССР ның кораллы көчләре Верховный Баш Командующие И. В. Сталинга Советлар Союзы Маршалы дигән хәрби исемне бирү турында

СССР ның кораллы көчләре Верховный Баш Командующие Иосиф Виссарионович СТАЛИНГА Советлар Союзы Маршалы дигән хәрби исемне бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

МОСКВА, КЕРМЛЬ. 6 МАРТ, 1943 ЕЛ,

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

6 нчы МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

6 нчы мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ржевтан көньяктарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр алга киттеләр һәм халык яши торган 30 дан артык пунктны, шул исәптән Осуга тимер юл станциясен алдылар. Һөҗүм итеп баручы совет частьлары берничә урында Осуга елгасын кичтеләр. Каты каршылык күрсәтүче дошманга каршы сугышларда 800 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде, шулар арасында 3 самолет, 57 танк, 8 орудие, күп кенә миномётлар һәм пулеметлар бар. 100 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең частьлар дошманга каршы ут сугышы алып бардылар. Н-че биеклекләр районында безнең сугышчылар немецларның контратакасын кире кайтардылар һәм 100 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Бер орудие, 70 винтовка һәм 6.000 патрон кулга төшерелде.

Ворошиловградтан көньяк - көнбатыштарак Н-че частьның хәрәкәттәге отрядлары дошманның тылына барып чыктылар һәм аңа атака ясадылар. Совет сугышчылары бер ротага якын гитлерчыларны юк иттеләр һәм немецларның 2 танкысын яндырдылар.

* * *

Харьковтан төньяк-көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары халык яши торган бер пунктны алдылар. Бу пункт өчен булган сугышларда 200 гә якын гитлерчылар, немецларның 2 танкысы, 4 орудиесе, сугыш припаслары төялгән 15 автомашинасы һәм ягулык тутырылган 6 автоцистернасы юк ителде.

* * *

Севскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Дошман каты каршылык күрсәтә һәм еш кына контратакаларга күчә. Н-че берләшмә частьлары, гитлерчыларның контратакаларын кире кайтарып, 400 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр һәм 100 кешене плен алдылар. Икенче бер участокта халык яши

(Ахыры 4 нче биттә).

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР ГЖАТСК ШӘҺӘРЕН АЛДЫЛАР

Ике тапкыр ясалган штурм нәтиҗәсендә безнең гаскәрләр ГЖАТСК шәһәрен алдылар. Кулга төшерелгән трофейларның исәбе алына.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Сәлам хатын укыганда

Фронттагыча эшләргә ант иттеләр

Район үзәгендәге клуб бинасы шыгрым тулы.

Колхозчылар, тракторчылар, агрономнар, укытучылар, совет, партия работниклары,— бөек ватан сугышының барлык фронтларында явыз дошманга каршы үз-үзләрен аямыйча көрәшүче батыр татар егетләренең ата-аналары, хатын-кызлары, абыйэнеләре, апа-сеңелләре, — фронтовикларга сәлам хат текстын тыннарын да алмыйча тыңлыйлар.

«Газиз улларыбыз һәм кызларыбыз! Сөекле ирләребез! Кадерле туганнарыбыз! Барлык татар халкының өмете сезгә текәлгән. Халык йөрәге сезнең белән тибә...».

Әйе, халык йөрәге фронт белән, фронтовиклар йөрәге белән бергә тоташкан. Сәлам хатының һәрбер юлы, һәрбер сүзе бу турыда тагын да бер тапкыр һәм бик ачык сөйләп бирә.

Хат укылып бетүгә залда көчле алкышлар яңгырый.

Митингта чыгып сөйләүче иптәшләрдән МТС директоры Дәүләтшин, район җир бүлеге мөдире Галиев, ВКП(б) райкомы секретаре Казаков һәм башкалар — дәүләт алдындагы барлык йөкләмәләрне үтәү, язгы чәчүгә уңышлы әзерлекне тәэмин итү, быел тагын да югарырак уңыш алып фронтовик егетләребезгә ярдәмне күп тапкыр арттыру кирәклеге турында сөйлиләр.

Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хат текстын уку, тикшерүгә багышланган митинглар Теләче районының барлык колхозларында да гаять зур күтәренкелек белән үттеләр. Бу митингларда колхозчылар үз өсләренә яңа йөкләмәләр алдылар. Сәлам хатны уку белән алар фронт өчен фронттагыча итеп эшләргә ант иттеләр.

Биргән вәгъдәне намус белән үтәрбез

Колхозчылар, колхозчы хатын-кызлар, агрономнар, укытучылар, хезмәткәрләр белән клуб шыгрым тулы. Ә килүчеләр һаман да күп әле. Алар фронттагы газиз улларына, сөекле ярларына татар халкының йөрәктән кайнап чыккан сәлам хатын тыңларга киләләр.

Хатны укыганнан соң, беренче сүз Күкчә Бирәзә авыл советы председателе иптәш Сафинга бирелә.

— Бу хатның язылуы без язгы чәчүгә әзерлекне төгәлләү алдында торган вакытка туры килә. Чәчү орлыкларыбыз бар. Кар тоту планын тулысынча үтәдек. Машиналарыбыз төзек. Атларыбыз көр. Без фронтовикларга биргән вәгъдәбезне намус белән үтәрбез, ди ул.

Аннан соң трибунага урта мәктәп директоры иптәш Сорокина чыга:

—Безгә радио көн саен яңадан-яңа хәбәрләр китерә. Фронттагы дусларга язылган хаттагы вәгъдәләрне без намус белән үтәрбез. Без йөкләмәләрне үтәү өчен җиң сызганып эшләрбез. Фронтовикларның балаларын тәрбия итүгә аеруча җитди игътибар бирербез,—ди иптәш Сорокина.

Сәлам хатны укуда Арча районының 29 авыл советыннан һәм 58 колхоздан 300 гә якын кеше катнашты. Алар Кызыл Армиябезгә ярдәмне киләчәктә берничә кат арттырырга вәгъдә бирделәр.

Фронт һәм тыл героиняларына дан!

„Эшче, инженер һәм техник хатын-кызлар! Һөҗүм итүче Кызыл Армиягә танкларны, самолетларны, орудиеләрне, пулеметларны, винтовкаларны, сугыш припасларын, киемнәрне тагын да күбрәк бирегез! Металл коюны, күмер чыгаруны, электр энергиясе җитештерүне арттырыгыз. Үз эшегезнең техникасын бик яхшы итеп үзләштерегез һәм хезмәт җитештерүчәнлеген туктаусыз күтәрегез“.

(ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ КАРАРЫННАН).

18 яшьлек Мария Овсянникова (Н-че завод эшчесе) Кызыл Армиянең яралы сугышчылары һәм командирлары өчен 7 нче тапкыр инде үзенең канын бирә. Канын биреп кайткан саен ул таныш булмаган сугышчыга хат яза. Рәсемдә: Мария Овсянникова хат яза.

К. Тахтеев фотосы.

ХӨРБИ БЕЛЕМНЕ ҮЗЛӘШТЕРӘЛӘР

Осоавиахим оешмасы председателе иптәш Маслова булган Н-че заводның тиры урнашкан бинада һәртөрле хәрби белгечлекләрне үзләштерү буенча бик күп төрле түгәрәкләр эшләп килә.

Менә тирга яшь төзүчеләр группасы килде. Алар 40 кеше. Танкистлар группасының чираттагы занятиесе башлана. Булачак танкистлар танкның материаль частьларын үзләштерәләр. Күрше бүлмәдә «Максим» пулеметын өйрәнү буенча занятие бара. Ә өченче группа—хатын-кызлар группасы. Бу патриоткалар снайперлар булырга әзерләнәләр.

Тир бинасында һәркөнне кызу эш кайный. Заводның яшь егетләре һәм патриотка хатын-кызлары белән беррәттән олы яшьтәге эшчеләр дә теге яки бу төрле белгечлекне үзләштерәләр. Алар үзләрен, теләсә нинди вакытта Кызыл Армия сугышчылары белән бер сафта басып, гитлерчы оккупантларга каршы ватан сугышында катнаша алырлык итеп әзерлиләр.

А. КУЗНЕЦОВ.

ИВАН КИРИЛЛОВИЧ ҺӘМ АНЫҢ КЫЗЛАРЫ

Иван Кириллович Константинов 3 нче номерлы фанера заводының электр хуҗалыгы белән җитәкчелек итә. Аның карамагында заводның бөтен нервлар системасы: меңнәрчә киловатт көчле электр моторлар, йөзләрчә яктырту точкалары, гигант электр прессы, телефон станциясе, дистәләрчә километрга сузылган ток үткәргеч чыбыклар һ. б., һ. б.

Бу катлаулы һәм җаваплы хуҗалык белән идарә итәр өчен Иван Кириллович үз тирәсенә егермеләп монтердан торган эшчеләр туплаган иде. Алар барысы да яшь, таза егетләр—кайсы коммутаторда яки контроль щита янында дежур тора, кайсы өзелгән чыбыкны ялгар өчен багана башына үрмәли, кайберләре исә цехларда күп санлы моторларның эшләүләрен күзәтеп йөриләр иде...

Кинәт сугыш башланып китте. Туган ил үзенең улларына кискен чакыру авазы ташлады.

— Барыгыз да ватанны саклауга!

Бу авазны бөтен халкыбыз белән бергә, Иван Кирилловичның уллары да ишеттеләр һәм сугышның беренче көннәреннән үк фронтка киттеләр. Алар киттеләр. Ә менә Иван Кириллович бер үзе «ятим» калды, һич югында ул үзе шулай уйлады башта.

Ләкин аның уллары китсә, кызлары калган иде әле.

Гитлер бандаларының илебезгә хыянәтчел тестә һөҗүм башлауларының беренче көннәрендә үк заводта җыелган митингта күп кенә хатын-кызлар трибунага менделәр һәм төрлесе төрле телдә, төрле җөмләләр белән бер үк фикерне әйттеләр.

— Аталарыбызның, абыйларыбызның, ирләребезнең станокларын һәм верстакларын ятим калдырмабыз. Бүгеннән үк фронтка киткән иптәшләрнең профессияләрен өйрәнә башларбыз. Тиз көндә алар урынына басарбыз!

Чыннан да шулай булып чыкты. Завод үзенең эшен туктатмады, алай гына түгел, ул үзенең эшен көчәйтте, чөнки бөек ватан сугышы шуны таләп итә иде. Ирләрнең калган эшен хатын-кызлар күтәреп алдылар һәм зур дәрт, теләк белән дәвам иттерә башладылар.

Озакламый Иван Кириллович участогында да комбинезон кигән кызлар күренделәр. Алар барысы да яшьләр, чибәрләр иде, ләкин эштә һичбер тәҗрибәләре юк иде. Иван Кириллович кашларын җыерды: «Болар белән ничек эшләрсең!»—диде. Шулай да, заводның тамыр тибүен туктатырга ярамый иде һәм ул зур түземлек белән үзенең яшь армиясен эшкә өйрәтергә керешә.

Баштарак, билгеле, ансат булмады: өйрәнү өчен вакыт та азрак иде, кайбер кызларда кыюсызлык, үз-үзенә ышанмаучанлык та бар иде. Алар өчен баганага үрмәләү «акробатлыгын» үзләштерү бигрәк тә читен булды.

Ләкин болар барысы да артта калдылар инде. Хәзерге көндә бөтен электр хуҗалыгы шушы кызлар күзәтүе астында. Аларның күбесе шактый ук җаваплы участокларда эшлиләр һәм үзләренең эшләрен зур ышаныч белән алып баралар.

Менә заводның йөрәге булган динамо машинасы. Аның янында төрле приборлар, рубильниклар белән тулган зур такта—бүлү щитасы. Щитадан төрле цехларга, поселокка юан-юан чыбыклар сузылган, алар буйлап көчле ток йөгерә һәм зур завод үзенең бөтен организмы белән хәрәкәткә килә. Гигант организмны төгәл ритм белән эшләтүче щита янында өч яшь кыз — Нюра Перова, Люба Калмыкова һәм Маруся Педо алмашып дежур торалар. Зур электр машинасының мондый яшь кенә кызларны санлавына аптырарсың! Электр челтәренең цехлардагы точкаларының эшен күзәтү өчен Тося Сереброва, Таня Кологреева һәм башкалар бар. Ә линиядә берәр хәл булса, хәзер үк Шәрәфетдинова, Катя Барынова һәм Тася Алексеевалар чыгып китәләр. Кирәк икән, алар тиен шикелле җитез генә үрмәләп баганага күтәреләләр.

Ася Большакова барысыннан да булдыклырак булып чыкты: менә бер ел инде ул заводның телефон станциясендә, коммутаторда эшли.

Шулай, завод гөрләп тора, моторлар өзлексез әйләнәләр, төннәрен цехларда яп-якты булып лампочкалар яналар, телефон элемтәсе үз тәртибендә. Димәк, кызлар сынатмадылар. Хәзер инде Иван Кириллович кашларын җыермый, ул бик канәгатьләнеп:

— Минем кызларым барысын да булдыралар алар,—ди.

Хатын-кызлардан электр - монтерлар әзерләүдә Иван Кириллович гаять күп көч куйды. Шуның өчен ул аларны хаклы рәвештә «минем кызларым» дип атый.

И. ФӘЙЗУЛЛИН.

Зеленодольск, 3 нче номерлы фанера заводы.

Баш инженеры иптәш Кадышев булган завод эшчесе иптәш Петухова фронтка киткән паяльщикны алыштырды. Ул үзенең яңа профессиясен яхшы үзләштерде һәм хәзер заданиене 400 процентка кадәр үтәп бара. Рәсемдә: иптәш Петухова эш өстендә.

К. Тахтеев фотосы.

ПАТРИОТЛЫК ҮРНӘГЕ

Ерактагы Томск шәһәреннән совет патриоткасы Мария Васильевна Октябрьскаяның хаты килде. Ул ватан өчен сугышларда үзенең ире — полковой комиссарның һәлак булуы турында, иренең үлеме өчен һәм гитлерчы палачлар тарафыннан җәзаланган барлык совет кешеләренең үлеме өчен үч алырга теләве турында иптәш Сталинга хат яза. Мария Васильевна үзенең 50.000 сум күләмендәге барлык саклык акчаларын танк төзү өчен Дәүләт банкысына кертkәнлеген хәбәр итә. Ул болай дип яза: «Танкка «Боевая подруга» дигән исем бирүне һәм шушы танкны йөртүче итеп үземне фронтка җибәрүне сорыйм. Минем шоферлык белгечлегем бар, пулеметны отлично беләм, һәм Ворошиловча атучы мин».

Бөек юлбашчы патриоткага рәхмәт белән җавап кайтарды һәм аның теләге канәгатьләндереләчәкне хәбәр итте. (ТАСС).

ВАТАН СУГЫШЫ КӨННӘРЕНДӘ СОВЕТ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

В. ГРИЗОДУБОВА

Подполковник, Советлар Союзы Герое

Халыкара хатын-кызлар көнен совет халкы хәзер немец-фашист басып алучыларга каршы рәхимсез һәм каты көрәш шартларында билгеләп үтә.

Азат ителгән хатын-кызларның нинди бөек көч икәнлеген һәм аңа көчләрнең һәм сәләтләрнең тулысынча чәчәк атуын тәэмин иткән дәүләтнең тормышында аларның роле ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлекне СССР үрнәгендә бөтен дөнья күрә.

Алар фронтта кабахәт дошманны тармар итүдә безнең сугышчыларыбызга батырларча һәм үз-үзләрен аямыйча ярдәм итәләр. Куркусыз совет кызлары көчле ут астында яраланган сугышчыларны сугыш кырыннан алып чыгалар. Госпитальләрдә алар аналарча ягымлылык белән яралы сугышчыларны тәрбиялиләр.

Тылда санитаркаларның һәм медсестраларның, фельдшерицаларның һәм врачларның яңа отрядлары үсеп чыкты. Элекке йорт хуҗаларының заводларга килделәр һәм станоклар янында урын алдылар. Алар шахталарга төшәләр, нефть скважиналарын бораулыйлар. Алар партия һәм совет органнарына җитәкчелек итәләр. Колхозлар белән идарә итәләр. Алар кызылармеецлар өчен кием-салымнар тегәләр, аларның семьялары турында кайгырталар. Алар сугышчылар белән чын йөрәктән язылган хатлар алышалар һәм яралы сугышчылар өчен үзләренең каннарын бирәләр. Безнең хатын-кызларыбызның бик күп төрле һәм яхшы нәтиҗәле барлык эшләрен санап бетерү кыен!

Севастополь өчен булган сугышларда 300 дән артык немецны юк иткән гүзәл снайпер Людмила Павличенконың исеме бөтен дөньяга билгеле. Бер көн эчендә сугыш кырыннан 21 яралы сугышчыны кораллары белән берлектә алып чыгып, военфельдшер Мария Лесовая да шунда ук дан казанды.

Санитария ротасы командиры Вера Крылова турындагы дан бөтен Көнбатыш фронтта яңгырый. Ул сугышның беренче көннәреннән үк үз ирке белән фронтка китә һәм аңа хәзер инде интендантлык хезмәте гвардия капитаны исеме бирелде. Розе шәһәренең элекке телефонисткасы Ольга Пинчук Кызыл Армиягә элемтәче булып барды һәм сугышның авыр шартларында бик күп тапкырлар элемтә линияләрен төзәтте. Ватан сугышы фронтларында дан казанган йөзләрчә һәм меңнәрчә кызларның исемнәрен китерергә мөмкин.

Совет хатын-кызы сугышка кадәр үк авиациядә почетлы урын алды. Фашистларга каршы сугыш көннәрендә дә ул моны саклап килә. Хезмәт бурычларын үтәгән вакытта һәлак булган гайрәтле очучы, Советлар Союзы Герое майор М. Раскова ватан сугышының беренче көннәреннән үк Хәрәкәттәге Армиянең хәрби очучылары сафында үзенең урынына басты. Ул бомбардировщиклар авиаполкының командиры иде.

Күптән түгел, Оборона Халык Комиссарының приказы буенча, 588 нче төнге бомбардировщиклар авиаполкы дошманга каршы сугышларда гайрәтлелек, нык торучанлык, батырлык, оешканлык һәм дисциплиналылык күрсәткән өчен гвардия полкы итеп төзелде. Бу полкның башында батыр командир—гвардия майоры Е. Д. Бершанская тора.

Дошман тылында халык өчен үч алучыларның сафларында ирләр белән бер дәрәҗәдә үз-үзләрен аямыйча безнең партизанкалар геройларча хәрәкәт итәләр. Гитлерчы көчләүчеләргә, үтерүчеләргә һәм талаучыларга карата аларның үз исәпләре бар. Немец басып алучылар власте астына эләккән азат совет хатын-кызлары кешелек кайгысының һәм җәфалануларының бөтен авырлыгын кичерделәр. Гитлерчы кабахәтләр хатын-кызның намусын мыскылладылар, аның кешелек дәрәҗәсен тартып алдылар, аны кол итеп әверелдерделәр. Фашистик башкисәрләр беркемгә дә мәрхәмәт күрсәтмиләр. Безнең аналарыбызның, хатыннарыбызның, сеңелләребезнең җәфа чигүләре һәм күз яшьләре үч алырга чакыралар. Һәм совет хатын-кызлары—партизанкалар, мөмкин булган бөтен средстволар белән дошманнан үч алалар.

Ватан сугышында катнашкан хатын-кызларның 1942 нче елның маенда Мәскәүдә булган митингысында Севастопольнең героик оборонасында катнашкан укытучы иптәш Федоринчик болай диде:

«Хатын-кыз буларак, мин әйтәм: фашизмнан да куркынычрак дошманыбыз юк безнең. Укытучы буларак, барлык культуралы кешелек дөньясы белән берлектә, мин бу караңгылык токымын ләгънәтлим. Ана буларак, мин, җирдәге барлык кешеләргә мөрәҗәгать итәм:—Әгәр дә безнең балаларыбызның тормышына фашизм куркынычы була икән, алар бәхетле булмаячак икәнлекне аңлагыз».

Совет укытучысының бу ялкынлы сүзләрендә безнең илебезнең миллионнарча хатын-кызларының фикерләре һәм хис.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

ЯХШЫ ӘЗЕРЛЕК ЧӘЧҮНЕҢ УҢЫШЛЫ ҮТҮЕН ХӘЛ ИТӘ

„Колхозчы хатын-кызлар, МТС һәм совхозларның эшче хатын-кызлары! Хәзер Кызыл Армияне һәм тылны азык белән тәэмин итү сезнең басуларда ничек эшләвегезгә бәйләнгән. Хәзер сез язгы чәчүнең уңышлы чыгуын хәл итәсез. 1943 нче елны югары иген уңышы алуны тәэмин итегез. Бөтенесе фронт өчен, бөтенесе җиңү өчен!“

(ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ КАРАРЫННАН).

БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘР

ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарлары район партия җыелышында җентекләп өйрәнелде. Язгы чәчүгә әзерлек буенча карарда күрсәтелгән кимчелекләр, билгеле, безнең район колхозларында да бар. Район партия җыелышы ул кимчелекләрне бетерү буенча конкрет чаралар билгеләде һәм хәзер пленум күрсәтмәләре күп кенә колхозларда тормышка ашырыла.

Буденный, Каганович исемендәге, «Красное ядро» һәм «Гудок» колхозлары соңгы көннәрдә язгы чәчүгә әзерлекне шактый көчәйттеләр. Орлык туплау, тазарту эшләре, инвентарьларга һәм сбруйларга ремонт ясау кызу темп белән бара. Хәзер инде бу колхозларның дүртесендә дә чәчү орлыклары тулысынча әзер дип әйтерлек.

«Красная нива» һәм «Новое Мамонино» колхозлары язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгына кушылдылар. Алар, язгы чәчүгә әзерлекне 10 нчы марттан да соңга калмый төгәлләргә йөкләмә алып, үзара социалистик ярыш договоры төзеделәр. Договор үтәлә. Бу ике колхозның икесендә дә чыннан да язгы чәчүгә әзерлек тәмам булып килә инде.

«Пятилетка», «Урал», «Кызыл байрак» һәм башка күп кенә колхозларда да фронт айлыгы башланды.

С. ДИМИТРОВ.

АЙЛЫККА КУШЫЛДЫЛАР

Лаеш районының «Яшәсен иркенлек» колхозында масса-аңлату эшләре күпләргә үрнәк булырлык итеп куелган. Колхоз партия оешмасы (секретаре иптәш Гайнуллин) бу мәсьәлә белән көн саен шөгыльләнә. Агитаторлардан Мәүлиева, Галиева һәм Юсупов иптәшләр бу эштә аеруча зур активлык күрсәтәләр. Фронт хәбәрләрен, Совет Информбюросы белдерүләрен, партия һәм хөкүмәт карарларын колхозчыларга вакытында җиткереп торалар. Алар моның өчен авылга газеталар килеп җиткәнне көтмиләр, радиодан файдаланалар. Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы үткәрү турында да шулай булды. Алар бу турыда ТАССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты карарын радио аркылы тыңлап, колхозчыларга шул көнне үк җиткерделәр. Нәтиҗәдә бу колхозда айлык шул көнне үк башланып китте. Колхозчылар язгы чәчүгә әзерлекне 15 нче марттан да соңга калмый төгәлләргә йөкләмә алдылар. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау төгәлләнеп килә инде. Айлык игълан ителү хәбәрен ишеткәч, тимерчеләрдән Салихов һәм аның ярдәмчесе Нигъмәтуллин иптәшләр тагын да тырышбрак эшкә керештеләр.

Ш. ШАКИРОВ.

СУГЫШЧАН БУРЫЧЛАР

Совет гаскәрләренең гаять киң фронтта һөҗүм сугышлары алып баруларына совет халкы тылда үз эшен тагын һәм тагын яхшырту белән, Кызыл Армиягә кирәк булганнарны торган саен күбрәк һәм күбрәк бирү белән җавап бирә. Һәм бу бик аңлаешлы да. Чөнки Советлар Союзындагы барлык халыкларның фикере, уе, көче бер төп бурычка—немец-фашист гаскәрләрен совет җирләреннән тәмам куып чыгару бурычына юнәлгән.

Дошманны тизрәк һәм тәмам җиңү өчен илне, Кызыл Армияне авыл хуҗалыгы продуктлары белән тагын да күбрәк тәэмин итү—барлык колхозчылар, МТС, совхоз эшчеләре, авыл хуҗалыгы белгечләре алдында торган иң беренче һәм изге бурыч.

1943 нче елда хәрби уңыш алынырга тиеш. Ә моның өчен язгы чәчүгә үрнәк төстә әзерләнергә, чәчүне уңышлы үткәрү өчен бөтен средстволардан, мөмкинлекләрдән тулы файдаланырга, колхозларда, совхозларда, колхозчыларда булган барлык резервларны тупларга кирәк.

«Кызыл Татарстан» ның 3 нче мартта чыккан номерында Апас районы, «Яңа ил» колхозы членнарының Татарстандагы барлык колхозчыларга, колхозчы хатын-кызларга мөрәҗәгате басылды. «Яңа ил» колхозы членнары республикабызның барлык колхозчыларын 1943 нче елда югары иген уңышы алу өчен язгы чәчүгә большевикларча әзерләнү буенча фронт айлыгы үткәрергә чакыралар. Алар үз өсләренә конкрет йөкләмә итеп: быел һәр гектардан кимендә 100 пот уңыш алуны, мәҗбүри йөкләмәләрдән тыш Кызыл Армия фондына 8.000 пот ашлык бирүне алалар. Алар үзләренең мөрәҗәгатьләрендә:

— Иптәш Сталинның приказына бердәм стахановча эш белән, язгы чәчүгә үрнәк рәвештә әзерләнеп һәм үткәреп җавап бирик. Быелгы елда фронтка һәм илгә ашлыкны, итне, сөтне, яшелчәләрне күбрәк бирик,—диләр.

«Яңа ил» колхозы членнарының бу чакыруы республикабызның барлык колхозчылары тарафыннан, һичшиксез, алкышлап каршы алыныр.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты «Яңа ил» авыл хуҗалыгы артеле членнарының язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы үткәрү турындагы тәкъдимен яхшы дип таптылар. Айлык 5 нче марттан 5 нче апрельгә кадәр үткәреләчәк.

Партиянең авыл райкомнарының, хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма комитетларының, МТС, совхоз политбүлекләренең, партиянең, комсомолның башлангыч оешмаларының бурычлары шуннан гыйбарәт ки, «Яңа ил» колхозы членнарының мөрәҗәгатен киң рәвештә тикшерүне оештырырга, һәрбер колхоз, МТС, совхоз буенча СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 27 нче февраль карары нигезендә, шулай ук ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарлары нигезендә конкрет чаралар билгеләргә, язгы чәчүгә үрнәк әзерлекне тәэмин итәргә тиешләр.

ТАССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты фронт айлыгының төп бурычлары итеп: СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1942 нче ел, 12 июль карарына тулысынча туры китереп, һәрбер колхозны һәм совхозны бөтен сабан басуына җитәрлек чәчү орлыгы белән тәэмин итүне, орлыкны чистартуны, сортлауны, тишелешләрен тикшерүне, тракторларга, тагылма һәм атка җигелә торган инвентарьга ремонтны төгәлләүне, кадрлар әзерләү һәм кышкы агротехника планнарын бер сүзсез үтәүне, атларны һәм кирәк кадәр санда мөгезле эре терлекләрне эшкә өйрәтүне, производство һәм эш планнарын төзүне куйдылар. Фронт айлыгында һәрбер колхоз, совхоз, МТС югарыда күрсәтелгән бурычларны тулысынча үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

ТАССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты карары нигезендә өлкә газеталары битләрендә Республика Почет тактасы оештырыла. Һәрбер МТС, совхоз, колхоз, бригада, звено, колхозчы, агроном, МТС һәм совхоз эшчесе, язгы чәчүгә әзерлекне большевикларча төгәлләп, Почет тактасына кертелү өчен көрәшергә тиеш.

Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы башланды. Фронт айлыгы фронт, ил таләп иткәнчә үткәрелсен!

«... ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ҮРНӘК БУЛЫРЛЫК ИТЕП ӘЗЕРЛӘНҮГӘ ҺӘМ АНЫ ҮТКӘРҮГӘ, ЮГАРЫ ҺӘМ НЫКЛЫ ИГЕН УҢЫШЫ ӨЧЕН КӨРӘШКӘ, КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ ЯРДӘМНЕ КӨЧӘЙТҮГӘ БАРЛЫК КОЛХОЗЧЫЛАРНЫ, КОЛХОЗЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ, МТС ҺӘМ СОВХОЗ ЭШЧЕЛӘРЕН, АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ БЕЛГЕЧЛӘРЕН ТУПЛАРГА, НЕМЕЦ-ФАШИСТ БАСЫП АЛУЧЫЛАРНЫ ТИЗРӘК ҺӘМ ТӘМАМ ТАР-МАР ИТҮ ӨЧЕН КИРӘК БУЛГАН ПРОДУКЦИЯНЕ ФРОНТКА ТАГЫН ДА КҮБРӘК ҺӘМ КҮБРӘК БИРҮНЕ ТӘЭМИН ИТӘРГӘ...».

(ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарыннан).

Рәсемдә: Әтнә районы, Киров исемендәге колхозның стахановчысы, сарык һәм бәрәннәр карауччы Галимә иптәш Сөләйманова.

АЛМАШ КЫЗУ ЭШТӘ

Ирләр фронтка киткәч, безнең колхозда да җаваплы күп кенә эшләргә хатын-кызлар күтәрелде. Алты бригадирыбызның бишесе хатын-кызлар. Шулай ук ферма мөдирлеген һәм ветсанитарлык эшен дә хатын-кызлар алып баралар. Алар үзләренең лаеклы алмаш икәнлекләрен бик тиз күрсәттеләр. Менә бригадир иптәш Хәкимова. Ул үткән елдан бирле генә әле бригадир булып эшли. Элекке бригадир Шәрипов бу бригаданың эшен өзеклеккә төшергән иде. Аз гына вакыт эчендә иптәш Хәкимова бригаданы алдынгылар сафына чыгарды. Шулай ук 4 нче бригада бригадиры Миңлебану иптәш Вәлиуллина да алдынгылардан санала. Бригада правление тарафыннан бирелгән нарядларны һәрвакыт төгәл үтәп бара. Яки менә фермада сарык караучы Хәдичә иптәш Гыйльманованы алыйк. Соңгы елны ул үзенең эшен күп тапкыр яхшыртты. Ул карый торган сарыкларның 26 сы быел икешәр бәрән китерде.

Дөресен әйтергә кирәк, безнең колхозыбыз сугышка кадәр кайбер елларны авыл хуҗалыгы эшләрен соңга калдыргалый иде. Ә менә үткән елны, шактый күп кыенлыклар булуга да карамастан, барлык авыл хуҗалыгы эшләрен вакытында башкардык. Дәүләткә һәм Кызыл Армия фондына ашлык тапшыру, МТС эше өчен натуралата түләү, ссуда кайтаруны вакытында үтәдек. Терлекчелек продуктлары тапшыру планнарын арттырып үтәдек.

Хәзер инде язгы чәчүгә әзерләнәбез. Чәчү орлыклары барлык культуралар буенча да җитәрлек күләмдә әзер. Сабаннарга, тырмаларга һәм культиваторларга ремонт төгәлләнде. Шулай ук арбалар да җитәрлек. Басуга 567 тонна тирес чыгардык, көл һәм кош тизәге әзерләү буенча бирелгән планнар үтәлде. Кар тоту да шулай ук яхшы үтте.

Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы игълан ителүне безнең колхозчыларыбыз алкышлап каршы алдылар. Бу айлык, һичшиксез, зур нәтиҗәләр бирәчәк.

Х. ГЫЙБАДУЛЛИН,

Чепья районы, «Кызыл юл» колхозы председателе.

ОТЛИЧНО БИЛГЕСЕНӘ

Чистай МТС ы янында оештырылган тракторчылар әзерләү курсында 78 кеше укый. Шуларның үтә күпчелеге хатын-кызлар. Алар бик яхшы тракторчы булып чыгу өчен көне-төне тырышып укыйлар. Маркина Зоя, Крылова Анастасия, Поликарпова, Ваничкина һәм башка күп кенә иптәшләр теория буенча да һәм шулай ук практика буенча да тик отлично билгеләре генә алып баралар. Алар хәзер тракторны йөртә дә беләләр инде.

Курс мөдире фронтовик иптәш П. Д. Астафиев (элеккеге тракторчы) курска оста җитәкчелек итә. Курсантлар өчен һәрьяктан уңайлы шартлар булдырылган. Яңадан ике атнадан курс үзенең эшен тәмам итәчәк.

ләре әйтеп бирелгән.

Халык өчен үзләренең тормышларын биргән Зоя Космодемьянская һәм Лиза Чайкиналарның онытылмаслык батырлыкларына яңадан дистәләрчә һәм йөзләрчә батырлыклар өстәлде.

Миллионнарча совет хатын-кызлары—яшьләре дә, картлары да—безнең тылыбызда үз-үзләрен аямыйча эшлиләр. Сугыш вакытында колхозда хатын-кыз хәлиткеч көч булып әверелде. Ул колхоз производствосының күп кенә хәлиткеч участокларында ирләрне алыштырды. Хатын-кызлар колхозларга җитәкчелек итәләр, тракторларны һәм комбайннарны йөртәләр, сабан артыннан баралар. Аларның бик күпләре администрация-хуҗалык, совет, партия һәм комсомол эшендә шундый сәләтлелек, шундый инициатива һәм totнаклылык күрсәтәләр ки, монә ирләр сокланыр иде.

Хатын-кызлар 1942 нче елның язгы чәчүендә яхшы эшләделәр. Мул иген уңышын җыеп алганда, алар үзләрен тагын да яхшырак күрсәттеләр.

Тракторчы хатын-кызлардан Бөтенсоюз социалистик ярышында 1942 нче елның язында 165.000 ләп кеше катнашты. Рязань өлкәсенең Рыбновский МТС ындагы комсомолка Даша Гармаш бригадасы үзенең уңышлары белән аеруча күренекле урын алды. Аның бригадасы һәрбер трактор белән планда билгеләнгән 487 урынына, 1.296 гектар җир сөрде. Йөзләрчә һәм меңнәрчә тракторчы хатын-кызлар икешәр, өчәр һәм хәтта дүртәр норма эшләделәр.

Промышленность производствосында совет хатын-кызы—работница һәрвакыт сизелерлек урын алып килде. 1939 нчы елда промышленностьта хатын-кыз инженерларның һәм техникларның 100 меңнән артык булуын, фәнни работникларның 12,5 мең булуын әйтү генә дә җитә. Сугыш көннәрендә исә промышленностька яңадан йөз меңнәрчә хатын-кызлар килделәр.

Мария Косогорова СССР дагы иң яхшы шахталардан берсенең мөдире булып эшли, Анна Рычкова Урал рудникларының атаклы бурильщицасы булып әверелде. Яшь эшче Анна Денисова «Калибр» заводында шлифовка буенча авыр бер эштә сменага 6 норма үти. Кузнецк металлургия комбинатында меңнәрчә кызлар һәм хатыннар станочниклар, слесарьлар, электриклар, автогенщиклар сварщиклар булып эшлиләр.

Хатын-кызлар танк, авиация, мотор, пушка, снаряд һ. б. эшли торган оборона заводларының цехларында, судйолар төзү верфьләрендә, тимер юл транспортында геройларча, үз-үзләрен аямыйча, ә еш кына ике кеше, өч кеше өчен эшлиләр. Аларның оста һәм җитез куллары фронтка китә торган миллионнарча снарядларны, патроннарны эшләп чыгаралар.

* * *

Кызыл Армия дүртенче ай буена 1.500 километр арадагы киң фронтта уңышлы һөҗүм алып бара. Гитлерчы шакшылардан инде 14 өлкә, край һәм автономияле республикалар азат ителде, дошманның 112 дивизиясе тар-мар ителде, һөҗүмнең өч ае эчендә дошманның 700 меңнән артык солдат һәм офицерлары юк ителде һәм 300 меңнән артыгы плен алынды, дошманның гаять зур сандагы техникасы юк ителде һәм безнең кулга төшерелде. Совет җиреннән дошманны масса төсендә куу башланды. Бу, совет патриотларының йөрәкләрен шатлык белән тутыра, аларга күтәренкелек һәм хезмәткә яңа батырлыклар өчен энергия бирә. Совет хатын-кызы Кызыл Армиянең җиңүләрендә аның хезмәтенең зур өлеше булу белән мактана.

Иптәш Сталинның Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган приказы халыкның иҗат көчләрен тагын да арттыруга чакыра. Чөнки дошман әле җиңелмәгән, ул әле көчле. Алда әле бик күп авырлыклар, мәхрүмлекләр һәм корбаннар тора. Безнең алда әле рәхимсез һәм каты көрәш тора.

Совет халкы Верховный Баш Командующийның приказына эш белән җавап бирә. Заводларда һәм фабрикаларда, колхозларда һәм совхозларда, бөтен илдә социалистик ярышның яңа дулкыны күтәрелә.

Сөекле ватаныбыз өчен тагын да зуррак энергия белән эшлик. Кабахәт, ерткыч һәм мәкерле дошманны җиңү өчен бөтен халык белән берлектә армый-талмый эшлик.

Немец басып алучыларга үлем!



Рәсемдә: Сулда — Орел өлкәсенең дошманнан азат ителгән Саломатовка авылы колхозчысы Аграфена Смалина бу авылга беренче булып килеп кергән совет автоматчигын—үзен коллыктан азат итүче Кызыл Армия сугышчысын кочаклап үбә. Уңда — ремонтланган бронемашиналар яңадан фронтка китәләр. ТАСС фотохроникасы.

Совет Информбюросыннан

6 нчы МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

торган бер пункт өчен бик каты сугышлар булды. Бу пункт берничә тапкыр кулдан-кулга күчте. Төнлә белән безнең сугышчылар дошманны аннан бәреп чыгардылар һәм үзләре кереп урнаштылар.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды дошманның кораллар һәм сугыш припаслары төялгән 3 хәрби эшелонын юлдан чыгарган, 3 паровоз, 70 ләп вагон һәм платформа җимерелгән. Шул ук отрядның партизаннары немецларның «Юнкерс-52» транспорт самолетын бәреп төшергәннәр. Самолетның 7 кешедән торган экипажы һәлак булган. Украина партизаннарының икенче бер отряды бер район үзәгендә урнашкан немецлар гарнизонына һөҗүм иткән һәм аны кырып бетергән. 19 винтовка, 7 автомат һәм берничә автомашина кулга төшерелгән.

* * *

Үзәк фронтның бер участогында немецларның 161 нче пехота дивизиясеннән бер группа солдатлар Кызыл Армия ягына чыктылар. Группа составында 15 поляк һәм 2 немец бар. Солдатларның берсе—Станислав П. болай диде: «Мин фронтка 27 нче февральдә килдем. Безгә һәрвакыт, немецлар армиясе җиңелмәслек дип әйтеп килделәр. Хәзер инде солдатлар «җиңелмәслек армиянең» бер-бер артлы җиңелүен күрәләр һәм немецлар пропагандасына ышанмый башлыйлар. География карталары янында еш кына фронттагы хәл турында кызу бәхәсләр туа. Кайбер солдатлар, кышкы һөҗүм вакытында русларның алган җирләре бөтен 1942 нче ел эчендә немецлар алган җирдән күбрәк икәнлекне әйтәләр. Офицерлар солдатларның фронттагы вакыйгаларны тикшерергә маташуларын тыярга тырышалар. Күптән түгел барлык солдатлардан Россиянең география карталарын җыеп алдылар».

* * *

Франция патриотлары немец оккупантларга каршы көрәшне көчәйтәләр. Азат укчылар дошманның коммуникацияләрен җимерәләр, тимер юлларда хәрәкәт составын юк итәләр. Кот-д'ор. департаментында немецларның сугыш йөкләре төялгән бер хәрби эшелоны юлдан чыгарылган. 22 вагон һәм бер паровоз җимерелгән. Грэ районында азат укчылар немецларның 2 поездын бәрелештерүне оештырганнар. Брестта патриотлар немецлар частенең штабына бомба ташлаганнар. Шартлау нәтиҗәсендә 18 гитлерчы үтерелгән.

6 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

6 нчы мартта безнең гаскәрләр ике тапкыр ясалган штурм нәтиҗәсендә Гжатск шәһәрен алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

5 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның кимендә 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар. 15 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 4 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Ржевтан көньяктарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм алып бардылар һәм халык яши торган берничә дистә пунктны алдылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Аларның саны алына. 1.000 нән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Пленныйлар алынды.

* * *

Безнең гаскәрләр Гжатск шәһәрен алдылар. Немецлар, табигый чикләрдән һәм Гжать елгасыннан файдаланып, шәһәргә килә торган барлык юлларны ныгыткан булганнар. Ржевтан кала Гжатск шәһәре дошман оборонасының аеруча көчле берничә терәк пунктларының берсе иде. Бик каты сугышлар нәтиҗәсендә безнең частьлар халык яши торган дистәләрчә пунктларны алдылар, шәһәрне төньяктан һәм көньяктан әйләнеп үттеләр һәм ике тапкыр штурм ясаганнан соң Гжатскины алдылар. Бу участокта булган сугышларда бүгенге көн эчендә генә дә бер полктан артык дошман пехотасы юк ителде. Кулга төшерелгән трофейларның саны алына.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че частьның разведка отрядлары дошманның бер терәк пунктына кинәт һөҗүм ясадылар. Безнең сугышчылар дошман гарнизонын кырып бетерделәр, 12 пулемет, күп кенә винтовкалар, 10.000 патрон кулга төшерделәр һәм терәк пунктка ныгып урнаштылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары дошман танкларына һәм пехотасына каршы сугышлар алып бардылар. Тулы булмаган саннар буенча, немецларның бер батальонга якын пехотасы кырып ташланды, дошманның 32 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Пехота кораллары уты белән немецларның 2 самолеты атып төшерелде.

* * *

Суджадан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктларның берсе районында дошман безнең подразделениеләргә каршы контратакага 10 танк җибәрде. Совет бронебойщиклары немецларның 5 танкысын зарарладылар. Дошманның калган танклары һәм алар артыннан килүче пехотасы, безнең позицияләргә килеп җитмичә, тиз генә чигенделәр.

* * *

Севскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Тирән кар һәм буран булута да карамастан, Н-че часть алга китте һәм халык яши торган 5 пунктны алды. 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Пленныйлар алынды һәм күп трофейлар кулга төшерелде. Совет элемтәчеләре үз-үзләрен аямыйча эшлиләр. Көчле буранда кызылармеец Бондарев ике сәгать эчендә 8 километр озынлыкта элемтә чыбыгы суздьг. Командиры сержант Хоботов булган отделениенең элемтәчеләре линиядә эшләгән чакта аларга 12 немец автоматчиты һөҗүм иткән иде. Элемтәче сугышчылар 5 немецны үтерделәр, ә калганнарын качарга мәҗбүр иттеләр. Отделение хәрби заданиене срогында үтәде.

* * *

Витебск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды февраль ахырында дошманның зур көчләренә каршы бик каты сугышлар алып барган. Совет патриотлары дошманның берничә атакасын бер-бер артлы кире кайтарганнар һәм 300 гә якын немец-фашист басып алучыларны кырып ташлаганнар.

* * *

Түбәндә Орел өлкәсенең Кубань авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немец басып алучылар Кубань авылына бәреп кергән вакыттан алып безнең өчен каторга тормышы башланды. Немецлар, һичбер сәбәпсез, Иван Марохин, Алексей Якушин, Фома Мельников, Иван Писарев дигән колхозчыларны һәм башка күп кешеләрне атып үтерделәр. Гитлерчы кабахәтләр Варвара Ж. ны көчләделәр, Марина Мельникованы мыскыл иттеләр һәм соңыннан аны үтерделәр. Авылның 200 дән артык кешесе немецлар комендатурасы подвалларында ятып чыкты. Анда аларны суктырдылар һәм төрлечә мыскылладылар. Фашистлар безнең авылны тәмам эштән чыгардылар, мәктәпне, сөт фермасын, колхоз каралтыларын һәм күп колхозчыларның йортларын җимерделәр. Бөтен авылда гитлерчы бандитлар тарафыннан таланмаган бер генә кеше дә юк, немецларның талаулары һәм җимерүләре эзе калмаган бер генә йорт та юк. Без ышанабыз, Кызыл Армия безнең газаплануларыбыз өчен немец-фашист үтерүчеләрдән үч алыр һәм туган совет җирен фашист үләксәләрдән чистартыр». Актка авыл советы члены Иван Королев, укытучы Анисья Рудакова, колхозчылардан Александр Хохаев, Оксана Лаврухина һәм башкалар кул куйган.

---

8 нче мартта, 19 сәгатьтә Татар дәүләт академия театры бинасында Казан шәһәренең партия, совет, профсоюз, комсомол оешмаларының һәм Казан шәһәре гарнизоны оешмаларының **ХАЛЫКАРА КОММУНИСТИК ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ТАНТАНАЛЫ УТЫРЫШЫ УТКӘРЕЛӘ.**

Билетлар ВКП(б) ның шәһәр райкомнары тарафыннан җибәрелә.

Союзниклар авиациясенең Германиягә һәм Голландиягә һөҗүме

ЛОНДОН, 5 март. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, кичә көндез белән Америка бомбардировщиклары Германиянең һәм Голландиянең төрле объектларына һөҗүм ясаганнар. Берләшмәләрнең берсе, дошман тарафыннан бер төрле дә каршылык күрсәтелүгә очрамыйча, немецларның әһәмиятле тимер юл узелы булган Гаммга кадәр барып җиткән. Бомбаларның туры төшкәнлекләре күренгән. Әйләнеп кайткан вакытта берничә тапкыр һава сугышы булган. Бу сугышларда дошманның 14 самолеты атып төшерелгән.

«Оча торган крепость» ларның икенче берләшмәсе Роттердамдагы верфьләргә һөҗүм ясаган.

Англия бомбардировщикларының берләшмәләре үткән төнне Көнбатыш Германиягә һөҗүм ясаганнар.

БЕРЛИННЫ БОМБАГА ТОТУ НӘТИҖӘСЕ

СТОКҺОЛЬМ, 5 март. (ТАСС). «Нюа даглигт аллеханда» газетасының Берлиндагы хәбәрчесенең язуына караганда, Берлинны бомбага тоту янгын командалары алдына чиктән тыш авыр бурычларны куйган. Аларга иң соңгы көчләрен биреп эшләргә туры килгән. Тиргартендагы һәм Берлинның көньяк-көнбатыш өлешендәге йортлар шактый зарарланганнар. Күп кенә семьяларда үтерелгән кешеләр бар. Берлин обер-бургомистры Штеерның халыкка чыгарган өндәмәсендә, соңгы вакытта бомбага тотудан башкалага килгән зарар бик зур икәнлеге һәм урамнарны ватылган әйберләрдән тазарту һәм биналарны төзәтү өчен Берлинда булган барлык эш көчләреннән файдаланырга кирәклеге күрсәтелә.

ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 5 март. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, кичә Седжанан шәһәрендә (Төньяк Тунис) сугыш дәвам иткән. Шәһәр урамнарында кызып киткән сугышлар нәтиҗәсендә дошманның атакасы туктатылган.

Франция гаскәрләренең алгы отрядлары 4 нче мартта Шотт Джерит күленең көнбатыш ягы буенда Нефтаны алганнар.

АЛБАНИЯДӘГЕ ХӘЛ

НЬЮ-ЙОРК, 5 март. (ТАСС). «Нью-Йорк таймс» газетасының хәбәр итүенә караганда, күптән түгел Италиянең Албанияне басып алган гаскәрләре арасында ачыктан-ачык күп кенә чуалышлар чыккан. Италиянең бер батальоны коралсызландырылган һәм Дураццодан конвой белән Италиягә озатылган. Итальяннар СССР га каршы сугышта катнашу өчен Албания легионы төзергә маташканнар, ләкин аңа керергә беркем дә риза булмаган.

ДАНИЯ ПАТРИОТЛАРЫНЫҢ ОККУПАНТЛАРГА КАРШЫ КӨРӘШЕ

СТОКҺОЛЬМ, 5 март. (ТАСС). Даниядә немецлар контроле астында чыга торган «Националь тиденде» газетасының баш мәкаләсендә язуына караганда, соңгы вакытта Даниянең төрле шәһәрләрендә күп кенә җитди диверсия актлары эшләнгән. Газета болай дип яза: «Күп сандагы диверсияләр һәм һөҗүмнәр нәтиҗәсендә, илдә килеп туган хәл чиктән тыш кыен булып тора».

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

— Немецлар Па-Де-Кале департаментында Германия армиясенә каршы саботаж актлары ясауда гаепләнгән 13 французга үлем җәзасы биреп үтергәннәр.

—Февраль аенда союзниклар Урта диңгездә дошманның 30 сәүдә пароходын һәм 2 су асты көймәсен батырганнар. Шулай ук танкерларга, баржаларга һәм башка корабльләргә күп кенә зарар китерелгән. Су асты көймәләренең берсе Италия ярлары буенда Генуэ заливында су өстенә чыгып, корабльләр эшли торган верфьләргә ут ачкан. Шунда эшләнә торган 2 корабльгә бик зур снарядлар төшкән һәм зур зарар китергән.

— Германиянең бер су асты каймәсе Бразилия ярларыннан ерак булмаган урында Испаниянең «Монте игельде» пароходына торпеда җибәреп батырган.

Җаваплы редактор И. УЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1074 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 393